| | | |
|---|---|---|
| **«Рассмотрено»**<br>Руководитель ШМО<br>__________/ Л.Н.Низамиева./<br><br>Протокол № 6<br>от «23» мая 2022 г. | **«Согласовано»**<br>Заместитель директора по ВР<br>МБОУ «Гимназия №6»<br>__________/ И.И.Яруллин/<br>«25» августа, 2022 г. | **«Утверждаю»**<br>Директор МБОУ «Гимназия №6»<br>__________/ Баклашова О.Н./<br><br>Приказ №192<br>от «25» августа, 2022 г. |

**Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение**
**«Гимназия №6» Приволжского района города Казани**

**Рабочая программа театрального кружка «Театральная студия-Манзара»**

**учителя татарского языка и литературы высшей квалификационной категории**
**Гариповой Гульшат Рафиковны**

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
Протокол №1 от 25 августа 2022 г.

**2022 - 2023 учебный год**

Пояснительная записка/а**ңлатма язуы.**

Балаларның акыл һәм хыялын, сөйләм культурасын, иҗади хезмәткә омтылышын тәрбияләү мәктәптә укытуның төп максатлары булып тора.

Рус телле укучыларны аралашырга өйрәтү, орфоэпик күнекмәләрне камилләштерү, чыгыш ясау осталыгын үстерү, татар телен өйрәнүгә кызыксыну булдыру зарурлыгын күздә тотып, театр түгәрәге программасы төзелде һәм дәрестән соң эшчәнлек оештырылды. Театр сәнгатенә караган материаллар, балалар өчен сәхнәләштерелгән әсәрләр, шигырьләр, милли фольклор бәйрәмнәре программаның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шулай ук спектакльләргә бару, видеофильмнар карау, күренекле артистлар белән очрашулар укучыларның театр сәнгате буенча осталыкларын үстерүдә зур урын алып тора.

**Программаның максаты:**

1. Укучыларны татар театр сәнгатен аңларга һәм образларны иҗат итәргә өйрәтү.
2. Татар театры тарихы, анын беренче карлыгачлары, беренчел адымнары белән кызыксыну хисләре уяту.
3. Татар театры сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, әхлак сыйфатлары формалаштыру, киләчәк тормышка әзерләү.
4. Сәнгатьле уку һәм сөйләм күнекмәләрен үстерү.
5. Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.

**Бурычлары:**

1. Театр сәнгатенең мәгънәсен аңлауларына ирешү.
2. Образларны тормышчан иҗат итү серләренә төшендерү.
3. Театрның үткән юлын, аның беренче яралгыларын аңлауларына ирешү.
4. Драма жанрының төрләрен аера алуларын булдыру.
5. Классик әсәрләр сәхнәләштерү.
6. Төрле бәйге-ярышларда, ата-аналар алдында чыгышлар ясау.
7. Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

**Шәхес үстерү нәтиҗәләре:**

- аралашу культурасын һәм кеше арасыда үзеңне дөрес тота белү кагыйдәләрен фориалаштыру;
- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

- театр эшчәнлегенә омтылыш,үз-үзеңне камилләштерергә теләкне үстерү;
- мөстәкыйльлек, җаваплылык, активлык, пөхтәлек сыйфатларын үстерү;
- танып белүне, мөстәкыйль фикерләү сәләтен активлаштыру.

**Белем бирү нәтиҗәләре (предмет):**

- танып белү процессларын үстерү: игътибар, күзаллау, хәтер, образлы һәм логик фикерләүне камилләштерү;
- татар телендә җөмләдә сүз тәртибен һәм басымны дөрес кую, авазларны дөрес әйтү күнекмәрен үстерү;
- сөйләмнең тавыш сыйфатларын үстерү: дөрес сулау, артикуляция, тавыш көче; гәүдәне иркен тотарга өйрәтү; фантазияне, пластиканы формалаштыру;
- театр һәм театр сәнгате тарихы белән таныштыру;
- актер осталыгының теоретик нигезләрен бирү;
- спектакль өстендә эш этаплары белән таныштыру;
- сәхнәдә хәрәкәт кагыйдәләре белән таныштыру;
- грим салырга өйрәтү;
- иҗади һәм оештыру сәләтләрен үстерү.

**Театр түгәрәге шөгыльләрендә сөйләм осталыгын үстерү максатында түбәндәге күнегүләрне үткәрү карала.**

1. Сүз басымын кую.
2. Сулыш күнегүләре.
3. Тартык һәм сузык авазларны дөрес әйтү күнегүләре.
4. Тавыш һәм дикция күнегүләре.
5. Текстның эчке мәгънәсен ачыклау.
6. Мәгънәви басым кагыйдәләре.
7. Сөйләм тизлеге.
8. Сөйләм ритмы һәм аһәңе.

Театр түгәрәге шөгыльләрендә сәнгатьле сөйләм осталыгына өйрәтү сәнгать осталары үрнәгендә, әдәби әсәрләр нигезендә һәм практик күнегүләр белән ныгытылып алып барыла.

Театр түгәрәге программасы 140 сәгатькә атнага 4 сәгать исәбеннән төзелде.

**Түгәрәк татар теле һәм әдәбияты программасын кабатларга тиеш түгел.**

Түгәрәкнең эш формасы күп төрле, монда укытучының иҗади сәләте зур роль уйный. Китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, укылган китап буенча киносценарийлар төзү, шигырь укучылар бәйгеләре оештыру, әдәби -музыкаль монтаж әзерләү, музейларга бару, җирле матбугат белән танышу, рецензия язарга өйрәнү, һ.б. бик күп төрле эш алымнары бар. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, телевизор, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра. Түгәрәк эше балаларның күзаллавын киңәйтергә, аңа яңалык алып килергә, рухи тәрбия бирергә дә тиеш. Халык авыз иҗатын, татар халык педагогикасын куллану, табигать белән аралашу түгәрәк эшләрен оештырганда укытучыга зур мөмкинлекләр ача.

**Программаны тормышка ашыру урыны**

*<u>Түгәрәк дәресләре өчен бүлмә</u>*: татар теле һәм әдәбияты кабинеты, актлар залы, театр кабинеты

**Җиһазлау:** телевизор, видео һәм аудиомагнитофоннар

**Күрсәтмәлелек:** Театр тормышыннан күренешләр; артистлар, режиссерлар, драматурглар турында рәсемле истәлекләр; сәхнә йолдызлары, Г.Камал, К.Тинчурин театрлары турында белешмә китаплар һ.б.

**Түгәрәкнең расписаниесе**

| Түгәрәк көннәре | Дәрес башлана | Дәрес тәмамлана |
|---|---|---|
| Сишәмбе | 13.30 | 16.30 |
| Пәнҗешәмбе | 13.30 | 16.30 |

**Календарь тематик план**

| № | ТЕМА | Үткәрү формасы | Сәг. саны | ҮТКӘРҮ ВАКЫТЫ (АЕ) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | Лекция | 1 | сентябрь |
| 2. | Оештыру эшләре. Түгәрәк әгъзаларының бурычлары. | Түгәрәк өстәл | 1 | сентябрь |
| 3-4. | Сәхнә теленең тормыштагы гади телдән аермасы. Хәрәкәтләр, мимика һәм гәүдә тотышы нәрсәләр турында сөйли? | Әңгәмә | 2 | сентябрь |
| 5-6. | Театр сәнгате, аның халык мәдәниятен үстерүдәге роле.<br>Театрның барлыкка килү, формалашу чоры. | Презентация карау | 2 | сентябрь |
| 7-8. | Беренче драматурглар иҗаты, театрның беренче карлыгачлары.<br>Татар театры. Ачык рәвештә куелу тарихы.<br>«Сәйяр» труппасы, аның иҗаты, йолдызлары. | Презентация карау, әңгәмә | 2 | сентябрь |
| 9. | Тизәйткечләр җыю, аларны өйрәнү. | Китапчык ясау | 2 | сентябрь |
| 10-11. | «Азат» әсәрен искә төшерү. Рольләрне кабатлау. | Практик эш | 2 | сентябрь |
| 12-13. | Сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр. Киемнәр әзерләү. Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. | Сүзләрне ятлау | 2 | сентябрь |
| 14. | Татар халык әкиятләре. Видеоязмалар карау. | Төркемләп | 1 | сентябрь |
| 15. | Габдулла әкиятләре белән танышу, бер әсәрне сайлап сәхнәләштерү | Әңгәмә, мультфильмын карау | 1 | сентябрь |
| 16-17 | Рольләргә бүлеп уку | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 18-19. | Сөйләм өстендә эш | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 20-21. | Аерым образлар өстендә эш | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 22-23. | Җырлар, биюләр өйрәнү | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 24-25. | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. Сәхнәгә кую. | Практик эш | 2 | октябрь |
| 26-27. | Яңа әсәрдән өзек куюга әзерләнү | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 28-29. | Рольләргә бүлеп уку | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 30-31. | Сөйләм өстендә эш | Төркемләп | 2 | октябрь |
| 32-33. | Аерым образлар өстендә эш | Индивидуаль эш | 2 | ноябрь |
| 34-35. | Сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр. | Төркемләп | 2 | ноябрь |
| 36-39. | Сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр. Киемнәр әзерләү. | Төркемләп | 4 | ноябрь |
| 40- | Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. Сәхнәгә кую. | Күмәк | 4 | ноябрь |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 43. | | | | |
| 44-47. | Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына бару, спектакль карау | Күмәк | 4 | ноябрь |
| 48. | Караган спектакль буенча әңгәмә. Образларны анализлау. | Әңгәмә, презентация | 1 | декабрь |
| 49. | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | Әңгәмә, презентация | 1 | декабрь |
| 50-51. | Хәрәкәтләр, мимика, һәм гәүдә тотышы нәрсәләр турында сөйли?<br>Кешенең хәрәкәтләре, мимикасы, гәүдәсен тотышы. Рәсем сәнгате һәм сынлы сәнгать әсәрләрен күзәтү. | Төркемләп | 2 | декабрь |
| 52-53. | Чыгыш ясаганда, аралашканда кешенең гәүдәсен тотышы һәм мимикасының роле. Мимика, хәрәкәтләр белән музыка астында төрле хис-кичерешләрне тасвирлап күрсәтүгә күнегүләр. Текстлардан өзекләр уку. | Төркемләп | 2 | декабрь |
| 54-55. | Сөйләм һәм яңгырау аппаратын күнектерү. Артикуляция һәм яңгырау аппаратына гимнастика күнегүләре. | Практик эш | 2 | декабрь |
| 56-61. | «Чыршы бәйрәме»: татарча җырлар өйрәнү, милли биюләр өйрәнү, татар халык уеннарын уйнау. | Индивидуаль эш<br>Төркемләп | 6 | декабрь |
| 62-70. | Г.Камал; К. Тинчурин иҗатлары;<br>Г.Камал, К. Тинчуринның әсәрләреннән өзекләр сәхнәләштерү;<br>-рольләргә бүлеп уку<br>-сөйләм өстендә эш<br>-аерым образлар өстендә эш<br>-сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр.<br>-сценарийны кабатлау. Хәрәкәтләр. Киемнәр әзерләү.<br>-сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. Сәхнәгә кую. | Төркемләп | 9 | декабрь-гыйнвар |
| 71-102. | **Яңа әсәрне сәхнәгә кую – 32 сәг.**<br><br>Әсәр сайлау, образлар сайлап, актерлык таләпләренә өйрәтү<br>-образлар сайлау, әсәрне өлешләп уку<br>-әсәрдән өзекләр өйрәнү<br>-әсәрне сәхнәгә куярга әзерләү<br>-әсәрнең ремаркалары буенча хәрәкәт итү<br>-әсәрдәге конфликтларны дөрес сүрәтләү юлларын өйрәнү<br>-әсәрне сәхнәләштерү алымнары<br>-әсәрне сәхнәгә кую дәресләре<br>-әсәрне нәниләр өчен кую<br>-әсәрдән өзекләрне сәхнәгә кую<br>-әсәрне видеоязмадан карау<br>(Хәрәкәтләр алымы)<br>-әсәрнең 2 нче пәрдәсе буенча эш<br>(өзек сәхнәләштерү яки образларга керү техникасы)<br>-рольләргә бүлеп уку<br>-сөйләм өстендә эш<br>-аерым образлар өстендә эш | Индивидуаль эш<br>Төркемләп<br>Практик эш | 32 | гыйнвар-февраль-март |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | -сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек.<br>-сәхнәгә кую. | | | |
| 103. | Эшләгән эшләргә анализ, нәтиҗә. | Төркемләп | 1 | март |
| 104<br>-<br>107. | Казан театрлары.<br>Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры. К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры.<br>М.Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры. Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры.<br>В.М.Качалов исемендәге рус драма театры. ”Әкият” татар дәүләт курчак театры. “Минем яраткан театрым” презентациясен төзү. | Практик эш | 4 | март |
| 108<br>-<br>109. | “Казан театрлары” темасына проект яклау. | Күмәк проект | 2 | март |
| 110<br>-<br>111. | Танылган драматургларыбыз. Туфан Миңнуллин - күренекле татар драматургы. Т.Миңнуллин әсәрләренә күзәтү, иҗатын өйрәнү, әсәрләен уку. | Әңгәмә, презентация | 2 | март |
| 112. | Танылган драматургларыбыз. Кәрим Тинчурин - татар драматургиясенең классигы, күренекле артист һәм режиссер. | Күмәк | 1 | апрель |
| 113<br>-<br>116. | Казанга Кәрим Тинчурин исемендәге театрына экскурсия оештыру. Спектакль карау. | Спектакль карау | 4 | апрель |
| 117<br>-<br>118. | “Танылган драматургларыбыз” темасына проект яклау. | Индивидуаль проект | 2 | апрель |
| 119<br>-<br>120 | “Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру. | Төркемләп | 2 | апрель |
| 121. | Сөйләм тизлеге. Сөйләм тизлегенә йогынты ясаучы күренешләрне анализлау.<br>Такмаклар, санамышлар әйтү. | Практик эш | 1 | апрель |
| 122. | Сөйләмнең интонацион-мелодик яңгырашы. Сөйләм агышында тавыш тоны үзгәрешенең типик очраклары белән таныштыру.<br>Шигъри әсәрләрне интонация белән уку күнегүләре. | Төркемләп | 1 | апрель |
| 123. | Шигъри әсәрләрне сәнгатьле уку.Шигырьдә ритм. Рифма төрләре.<br>Шигырьдә ритм төзелешен саклау кагыйдәләре. | Төркемләп | 1 | апрель |
| 124<br>-<br>127. | Г.Тукай, М.Җәлил шигырьләрен сәнгатьле уку. Шигырь конкурсына әзерләнү һәм катнашу. | Индивидуаль эш | 4 | апрель |
| 128<br>-<br>131. | Казанда, республика буенча уза торган бәйгеләрдә катнашу, аларны бергәләп карау, әңгәмә дәресләр уздыру | Төркемләп | 4 | Ел буе |
| 132<br>-<br>135. | “Ак чәчәкләр” спектаклен карау. Г.Кариев театры артистлары белән очрашу | | 4 | май |
| 136 | **Йомгаклау дәресләре** | Практик эш | 5 | май |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| -<br>140 | Мәктәп укучылары, әти-әнилэр алдында спектакльнең премьерасын кую<br>Иҗат эше, уңышлар турында мәкалә язу, интернет челтәрендә яңалыкларны чагылдырып бару.<br>Зачет дәрес<br>Театр сәнгате, театр тарихы һәм аның тормыштагы әһәмияте<br>Эшләгән эшләргә анализ, нәтиҗә. | | | |

**Башлангыч сыйныф укучылары белән эшләү планы**

**Максат:** укучыларны татар театр тарихы, аның үткәне һәм бүгенге иҗаты белән кызыксындыру, театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, аларда әхлак сыйфатлары формалаштыру.

**Бурычы:**

-Татар театры белән кызыксындыру, милли хисләр уяту;
-Киләчәк тормыш өчен милли рухлы шәхес үстерү;
-Сәхнә тормышына лаеклы алмаш әзерләү.

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Үткәрү урыны |
|---|---|---|---|
| 1<br><br><br>2 | Ата-аналар белән эш:<br>А) ата-аналар җыелышы<br>Б) аерым әңгәмәләр<br>Чаралар:<br>- «Көзге бал»<br>- Театр көне<br>- Чыршы бәйрәме<br>- Театр бәйгесе<br>- 23 февраль, шигырь сөйләү бәйгесе<br>- 8 март<br>- Юмор кичәсе, “Каз өмәсе”<br>- Балалар өчен сәнгать фестивале | <br>Чирек саен<br>Даими<br><br>Октябрь<br>Ноябрь<br>Декабрь<br>Январь<br>Февраль<br>Март<br>Апрель<br>Апрель-май | <br>Класс,<br>мәктәп<br><br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп<br>Мәктәп |